# КАРАР

**28 ноябрь 2020 ел** **№1**

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлегенең Өркеш авылы гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде, сход 26, 27, 28 ноябрь 2020 елда утте.:

"Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләре укучылары, I төркем инвалидлары, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк пенсионерлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлегенең Өркеш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Тау асты урамында юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, ком, вак таш җәю), проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелек;
- җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)
- кышкы чорда территорияне кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары сатып алу,

запас частьләр, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)

- Өркеш авылында артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу;;
- Тау асты ур., Өркеш авылы (2 скважина) буенча артезиан скважиналарыннан файдалануга лицензия алу өчен документлар пакетын һәм лаборатория тикшеренүләрен әзерләү чараларын тормышка ашыру . );
- Тау асты ур., Өркеш авылларында янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Өркеш авылында энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру.
- торак пунктны төзекләндерү ,балалар мәйданчыгы Мафлары тирәсендә коймалар алу һәм урнаштыру);
- Өркеш авылында видеокүзәтү камераларын сатып алу һәм урнаштыру (техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, сатып алу, урнаштыру, карап тоту, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

« БЕЗ РИЗА» « БЕЗ КАРШЫ»»

Халык җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 169 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 87 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар өчен түбәндәге урыннар билгеләнде::

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашучы 87 кеше тавыш бирде;

«юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлегенең Өркеш авылы халык җыенын узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга

2. 2021 елда үзара салым суммасын 800 сумга кадәр арттырырга, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләре укучылары, I төркем инвалидлары, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк пенсионерлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлегенең Өркеш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән үзара салым кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтергә:

- Тау асты урамында юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, ком җәю, вак таш җәю), проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелек;

- җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)

- кышкы чорда территорияне кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, запас частьләр, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)

- Тау асты ур., Өркеш авылында янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Өркеш авылында энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру.

-балалар-спорт мәйданчыгы янындагы территорияне төзекләндерү , МАФлар, тренажерлар урнаштыру өчен территорияне планлаштыру; әлеге территорияне яшелләндерү, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру)

- Өркеш авылында видеокүзәтү камераларын сатып алу һәм урнаштыру (техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, сатып алу, урнаштыру, карап тоту, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- карарны кабул ителгән итеп санарга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль

берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Өркеш авыл җирлеге башлыгы: А.Ш.Әгләмова